**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **с. Тюлячи** **КАРАР**

**«20» январь 2023г.** **№ 5**

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 10 октябрендәге 196 номерлы «Гражданнарны Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакыруга бәйле рәвештә мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы мәгариф оешмаларында эшчәнлекне җайга салу турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

МКУ «Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты мәгариф бүлеге»нең 2022 елның 26 декабрендәге 397 номерлы хатын карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Хәрби көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 14 ноябрендәге 1213 номерлы карары нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 10 октябрендәге 196 номерлы «Гражданнарны Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакыруга бәйле рәвештә мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы мәгариф оешмаларында эшчәнлекне җайга салу турында» карарына (09.12.2022 № 263 карар редакциясендә), түбәндәге тәртиптә 4 пунктны бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«4. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 10 октябреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.».

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче И.Х Хәмидуллин